# «Минем гаиләм»
# «Моя семья»



*“Гаилә ул- җылы учак. Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык шулкадәр көчле була”*

*Максат:*

- *“Гаилә” төшенчәсенең асылын аңларга ярдәм итү;*
- *Әти-әниләргә, өлкәннәргә, туганнарга ихтирамлы, игътибарлы булырга өйрәнү;*
- *Кешелеклелек, ярдәмчеллек, игелеклелек сыйфатлары тәрбияләү.*
- *“Әти-әни, мин – бердәм гаилә.”*

# Габдулла Тукай
## Безнең гаилә



- ***Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи — Безнең өйдә без җидәү: безнең, песи — җиденчесе.***

- ***Бергә ашый, чәй эчә, безнең белән бергә йоклый ул, Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.***

# Минем гаиләм



# Мин бик бәхетле бала – минем зур гаиләм бар. Зур гаиләбез белән бик горурланам

Минем исемем - Фирүзә

Миңа 9 яшь

Минем гаиләм:

әтием – Фәнис

әнием – Чулпан

апам – Гөлназ

әбием – Мәһинур

Без тату гаилә булып зур өйдә яшибез.





- *Гаилә – безнең өебез, әби-бабай, әти-әни, мин, туганнарым.*
- *Гаилә – ул йорт кебек, ә нигезе нык булмаган йорт җимерелә.*
- *Әти-әни йортның томкасы, ә балалары – аның көзгесе.*

# *Безнең кадерле кешеләребез*

- *-Дөньяда иң якын, иң газиз кешеләр – әти-әниләр*
- *- Әниләребез назлы карашлары, йомшак куллары белән шатландыра*
- *- Әтиләребез көчле, батыр, уңган булулары белән безне куандыра*

# Әбиемә – дан җыры

*Үсеп җиткәч ,инде кеше булгач,*
*Әбиләрне ташлап китмәгез.*
*Ташлап китеп, картлык көннәрендә*
*Сез аларны ятим итмәгез.*
*Әбиләрнең бөтен мәхәббәте*
*Бөтен мәрхәмәте-балага.*
*Әбиләргә дигән җан җылысы*
*Адашып йөрмәсен иде далада.*

# *Ике әбием һәм бабам белән мин һәрвакыт бергә*

# *Дәү әни таба ашлары пешерергә оста. Аннан мин дә өйрәнәм*



# *Татар халык ашлары белән сыйлыйм гаиләмне*





# Дәү әнием дәрес әзерләргә дә булыша



# Дәү әниемнән кул эшләренә өйрәнәм



# Кич белән дәү әнием һәм әбием белән китап укырга яратабыз



# Биергә бик яратам,
# һәр бәйрәмдә катнашам





# *Мәҗит Гафури “Ата-ана”*

*Сөямен чын күңел белән үземнең әткәй-әнкәмне;*

*Яраткан барча нәрсәдән алар матур, алар ямьле.*

*Сабый чакта күземне ачкач ук күрдем мин аларны,*

*Сөям мин шул вакыттан бирле бу хөрмәтле җаннарны.*

*Күтәргәннәр авырлыклар минем өчен җаннары тынмый*

*Киендергән, ашатканнар, тузан чаклы авырсынмый.*

